**Электрон журналга**

Вакланмалы-сызыкча функция

(IX сыйныфта математика дәресе)

**Раилә ГАРИФУЛЛИНА,**

*Балтач районы Түнтәр урта мәктәбенең югары квалификация категорияле математика укытучысы*

**Максат.** Вакланмалы-сызыкча функция һәм асимптота тигезләмәләре төшенчәсен бирү; вакланмалы-сызыкча функциянең билгеләнү һәм кыйммәтләре өлкәсен, графигын төзү күнекмәләре булдыру; укучыларда математик культура тәрбияләү.

**Кулланылган җиһазлар һәм әсбаплар.** Ноутбук, проектор, интерактив такта, координаталар яссылыгы һәм анда у= 6/х функциясе графигы, рефлексия картасы, мультимедиа презентациясе, дәреслек (Алгебра: гомуми белем бирү мәктәбенең IX сыйныфы өчен дәреслек/ Ю.Н. Макарычев, Н.Г.Мендюк, К.И.Нешков, С.Б.Суворова; С.А.Теляковский редакциясендә /М.: Просвещение, – 2004 / Татарчага тәрҗемә, Казан: Мәгариф, 2009).

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру өлеше.**

**Максат.** Исәпләү күнекмәләрен үстерү; үтеләчәк темага бәйле теоретик материалларны һәм кагыйдәләрне кабатлау.

Хәерле көн! Дәресебезне башлап җибәрәбез.

Слайдка игътибар итик әле.

функциясе бирелгән

1. Вакланмалы-сызыкча функцияне стандарт рәвешкә китерегез һәм асимптота тигезләмәләрен языгыз.

2. Функциянең билгеләнү өлкәсен табыгыз.



3. Функциянең кыйммәтләре өлкәсен табыгыз.- Өй эшен тикшереп алыйк (*1– 4нче слайдлар*):

1. 1 нче биремнең 3 нче соравына җавабыгызны әйтегез. (*24*)
2. 2 нче биремдәге аңлатманың кыйммәтен табыгыз.

**2 нче бирем.**

Аңлатманың кыйммәтен табыгыз:

$$\frac{18x+9}{1+2x} - \frac{6-3x}{x-2} = \frac{9(2x+1)}{2x+1} + \frac{3(2-x)}{2-x} = 9+3=12$$

3. 3 нче биремнең җавабы ничек булды?

**3 нче бирем.** Квадрат тигезләмәнең икеләтелгән тамырлары суммасын табыгыз:

$$x^2 - 1006 \cdot x + 1005 = 0.$$

Виет теоремасына кире теорема нигезендә тамырлар суммасы капма-каршы тамга белән икенче коэффициентка тигез 1006 ·2=2012

Телдән исәпләү күнекмәләре: *(5 нче слайд)*




-

**Нәтиҗә.** Вакланмалы сызыкча функция.

*(нәтиҗәне полядагы число турысына язып куйдык)*

Шулай итеп, бүгенге дәресебезнең темасы: «Вакланмалы-сызыкча функция».

Юлга чыкканда һәрвакыт юл йөрү кагыйдәләрен белү кирәк. Аларның ике төрен без һәрвакыт истә тотарга тиеш.

Игътибар! *(6 нчы слайд)*




**Нәтиҗә.**

• Тискәре саннан җөп дәрәҗә тамыр алынмый.

• Дөрес аңлатма, җавап: -2.

• Дөрес аңлатма, җавап: 0.

• Нольгә бүләргә ярамый!

Геометрик фигуралар эчендәге бердәйлекләргә игътибар итик:

1: $\frac{a}{b}+\frac{c}{b}=\frac{a+c}{b}$ ; 2: $\frac{a-c}{b}=\frac{c}{b}-\frac{a}{b}$ ; 3: $\frac{a(x-1)}{1-x}=$ **a** . *(7 нче слайд)*

*(1: Дөрес тигезлек, 2:* $\frac{a-c}{b}=-\frac{c}{b}+\frac{a}{b}$ ; *3:* $\frac{a(x-1)}{1-x}=-a$ *)*

**II. Яңа тема өйрәнү.** *(8 нче слайд)*

**Максат.** Координаталар яссылыгында бирелгән графикның нинди функциянеке булуын ачыклау; функция графигын ординаталар һәм абциссалар күчәре буенча параллель күчерү нәтиҗәсендә килеп чыккан функциянең формуласын язарга өйрәтүгә нигезләнеп вакланмалы – сызыкча функциянең

графигын төзүне, аның билгеләнү һәм кыйммәтләре өлкәләрен билгеләүне формалаштыру.

***Сезгә координаталар яссылыгында*** функция графигы бирелгән. Ягез, ачыклагыз әле, бу нинди функция графигы?

VIII сыйныф курсыннан билгеле булган функциясен карап китик әле.

- Бирелгән функциянең билгеләнү өлкәсе нинди булыр? (*юл йөрү кагыйдәләрен искә төшерик*)
- Функция графигының үсү һәм кимү аралыкларын күрсәтик.
- Функция уңай һәм тискәре кыйммәтләр алган аралыкларны билгелик;
- Ә хәзер, функция графигын Охлар (абциссалар) күчәре буенча 1 берәмлеккә күчерик;
- Нинди функция графигы сурәтләнде? Формуланы чыгарыйк әле.

($y = 6/(x - 1)$)

- Ә хәзер, функция графигын Оу лар (ординаталар) күчәре буенча 2 берәмлеккә күчерик;
- Нинди функция графигы сурәтләнде? Формуланы чыгарыйк әле.

($y = 6/(x - 1) + 2$)

- X=1 һәм y= 2 турылары асимптоталар дип атала.
- Каян белдегез?

Афәрин! Бик дөрес. Ә хәзер нәтиҗә ясыйк.

**Нәтиҗә.** Димәк, рәвешендә бирелгән функциянең графигын төзү өчен: $y = \frac{k}{x}$

функциясе графигын Ох лар (абциссалар) күчәре буенча m берәмлеккә күчерергә һәм Оу лар (ординаталар) күчәре буенча n берәмлеккә күчерергә кирәк.

Вакланмалы сызыкча функциягә мисаллар:

$y = \frac{2x-5}{3x+4}$; $y = \frac{6}{10x-7}$ $y = \frac{x+4}{2x}$

; .

Гомумән, вакланмалы сызыкча функция дип $y = \frac{ax+b}{cx+d}$ формуласы белән бирергә мөмкин булган функция атала, монда x –үзгәрешле (агумент), a,b,c һәм d – иректе саннар, өстәвенә $c\neq0$ һәм $ad-bc\neq0$.

$c\neq0$ һәм $ad-bc\neq0$ чикләүләре урынлы, әгәр c=0 булса сызыкча функция килеп чыга.

Әгәр ad-bc=0 булса, кыйммәте $\frac{b}{c}$ кыскартылучы вакланма, ягъни константа килеп чыга.

**III. Үтелгән теманы ныгыту.**

**Максат.** Бирелгән вакланмалы-сызыкча функция формуласын рәвеш үзгәртүләр кулланып рәвешенә китерү күнекмәсен булдыру; асимптота тигезләмәләрен язуны һәм функция графигын төзүне камилләштерү.

**Мисал -1:**

$y = \frac{2x+4}{x-1}$

функциясенең графигын төзегез.

**Чишү.** Бирелгән функцияне рәвешенә китерәбез. Моның өчен рәвеш үзгәртүләрне кулланабыз.

$= \frac{2(x-1)}{x-1} + \frac{6}{x-1} = 2 + \frac{6}{x-1}$. (слайд-10)

**Сәламәтлек минутлары.** *(Дежур укучы хәрәкәтләр эшләтә.)*

**Максат.** Укучыларның сәламәтлекләрен, физик күнегүләр эшләтү һәм ял минутлары белән ныгыту.

**Төркемнәргә эш.**

**Максат.** Кеше фикерен тыңлый һәм үз фикерен җиткерә белүне формалаштыру; лидерлыкка сәләтле шәхес тәрбияләү; укучыларда математик культура тәрбияләү.

| | |
|---|---|
| **I вариант.**<br>$y=\frac{x-4}{x-3}$ функциясе бирелгән<br>1. Вакланмалы – сызыкча функцияне стандарт рәвешкә китерегез һәм асимптота тигезләмәләрен языгыз.<br>2. Функциянең билгеләнү өлкәсен табыгыз.<br>3. Функциянең кыйммәтләре өлкәсен табыгыз. | **II вариант.**<br>$y=\frac{2x-1}{x-1}$ функциясе бирелгән<br>1. Вакланмалы – сызыкча функцияне стандарт рәвешкә китерегез һәм асимптота тигезләмәләрен языгыз.<br>2. Функциянең билгеләнү өлкәсен табыгыз.<br>3. Функциянең кыйммәтләре өлкәсен табыгыз. |
| **III вариант.**<br>$y=\frac{3x+2}{x+3}$ функциясе бирелгән<br>1. Вакланмалы-сызыкча функцияне стандарт рәвешкә китерегез һәм асимптота тигезләмәләрен языгыз.<br>2. Функциянең билгеләнү өлкәсен табыгыз.<br>3. Функциянең кыйммәтләре өлкәсен табыгыз. | **IV вариант.**<br>$y=\frac{3x-2}{x-2}$ функциясе бирелгән<br>1. Вакланмалы-сызыкча функцияне стандарт рәвешкә китерегез һәм асимптота тигезләмәләрен языгыз.<br>2. Функциянең билгеләнү өлкәсен табыгыз.<br>3. Функциянең кыйммәтләре өлкәсен табыгыз. |

*(Эшен тәмамлаган төркем тактада үз эшен тәкъдим итә. Эшләргә анализ ясала, фикер алышына һәм нәтиҗә ясала.)*

**IV. Йомгаклау өлеше.**

**Максат.** Теоретик һәм гамәли эшчәнлеккә нәтиҗә ясау; укучыларга дәрестәге үз эшчәнлекләренә бәя бирүне камилләштерү; рефлекция ярдәмендә укучыларуың дәрес материалын үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау.

**Укытучы.** Укучылар! Дәресебез азагына якынлаша, үзегезнең эшчәнлеккә бәя биреп карагыз әле. Сезнең алдыгызда рефлексия өчен таблица куелган. Шул таблицаны тиз генә тутырып миңа җибәрегез.

Фамилияң, исемең ______________________________

| Дәреснең этаплары | Дәрес этапларының катлаулылыгын билгеләү | | | Кәефегез | Үзегезнең эшчәнлегегезгә бәя (1 – 5 балл) |
|---|---|---|---|---|---|
| | **җиңел** | **уртача** | **авыр** | | |
| Оештыру өлеше | | | | | |
| Яңа тема үзләштерү | | | | | |
| Функция графигын төзү күнекмәсен формалаштыру | | | | | |
| Төркемнәрдә эш | | | | | |
| Гомуми нәтиҗә | | | | | |

**Өй эше.**

**Максат.** Имтиханга әзерлекне ныгыту.

[п.10* укырга, №180(а), 181(б).]

ГИА га әзерлек: (*Виртуаль факультативта бирем*) 19.00 – 20.00 сәгать аралыгында чишелеше буенча фикер алышу, 20 сәгать 10 минутта – видеоэлемтә.

*(Skype да төркем белән эш.)*